ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО БИОЛОГИЧЕСКИМ РЕСУРСАМ
ул. Карима Тинчурина, д. 29, г. Казань, 420021

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИОЛОГИК РЕСУРСЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ
К. Тинчурин ур., 29 йорт, Казан шәһәре, 420021

Телефон:(843)211-66-94, E-Mail:ojm@tatar.ru, сайт:http://ojm.tatarstan.ru

Приказ　　　　Казан шәһәре　　　　Боерык

05.02.2026　　　　№ 48 - од

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2021 елның 11 февралендәге 40-од номерлы боерыгы белән расланган Тиешле рөхсәтсез саклана торган яки Татарстан Республикасы территориясендә табылган коралны, хәрби кирәк-яракларны, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне үз ихтыяры белән тапшырган гражданнарга акчалата бүләкләү билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертү хакында

«Республика башкарма хакимият органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 2022 елның 28 февралендәге 175 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә боерам:

1. Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2021 елның 11 февралендәге 40-од номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы

Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2021 елның 03 ноябрендәге 340-од номерлы боерыгы белән кертелгән үзгәрешләр белән) белән расланган Тиешле рөхсәтсез саклана торган яки Татарстан Республикасы территориясендә табылган коралны, хәрби кирәк-яракларны, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне үз ихтыяры белән тапшырган гражданнарга акчалата бүләкләү билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына, яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә (кушымта итеп бирелә).

2. Рәис урынбасарларына, структур бүлекчәләр җитәкчеләренә, дәүләт хезмәтләре күрсәтүне турыдан-туры тәэмин итүче затларга регламентларның нигезләмәләрен үтәүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә, дип билгеләргә.

Рәис Ф.С. Батков

Татарстан Республикасы Биологик
ресурслар буенча дәүләт
комитетының 2021 елның 11
февралендәге 40-од номерлы
боерыгы белән расланган
(Татарстан Республикасы
Биологик ресурслар буенча дәүләт
комитетының 05.02.2026 № 48- од
номерлы боерыгы редакциясендә)

**Тиешле рөхсәтсез саклана торган яки Татарстан Республикасы территориясендә табылган коралны, хәрби кирәк-яракларны, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне үз ихтыяры белән тапшырган гражданнарга акчалата бүләкләү билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Тиешле рөхсәтсез саклана торган яки Татарстан Республикасы территориясендә табылган коралны, хәрби кирәк-яракларны, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне үз ихтыяры белән тапшырган гражданнарга акчалата бүләкләү билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты(алга таба – Регламент) тиешле рөхсәтсез саклана торган яки Татарстан Республикасы территориясендә табылган коралны, хәрби кирәк-яракларны, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне үз ихтыяры белән тапшырган гражданнарга акчалата бүләкләү билгеләү һәм түләү буенча карар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (алга таба – дәүләт хезмәте) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Гариза бирүчеләр: рөхсәтсез саклана торган яки Татарстан Республикасы территориясендә табылган коралларны, хәрби кирәк-яракларны, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне ирекле рәвештә тапшырган 18 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк гражданнар (алга таба – гариза бирүче).

Гариза бирүче исеменнән ышаныч кәгазе һәм аның шәхесен раслый торган документлар нигезендә ул вәкаләт биргән физик зат эш итә ала.

1.3. Дәүләт хезмәте гариза бирүчеләрнең категорияләре (билгеләре) нигезендә күрсәтелә, алар турында белешмәләр «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) Бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында (http://www.gosuslugi.ru/) (алга таба –Бердәм портал), шулай ук «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырыла.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Дәүләт хезмәте атамасы

Тиешле рөхсәтсез саклана торган яки Татарстан Республикасы территориясендә табылган коралны, хәрби кирәк-яракларны, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне үз ихтыяры белән тапшырган гражданнарга акчалата бүләкләү билгеләү һәм түләү

2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган исеме

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты (алга таба – Комитет).

Дәүләт хезмәте Комитетның административ һәм суд практикасы бүлеге (алга таба – Бүлек) тарафыннан күрсәтелә.

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе:

- тиешле рөхсәтсез саклана торган яки Татарстан Республикасы территориясендә табылган коралны, хәрби кирәк-яракларны, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне үз ихтыяры белән тапшырган гражданнарга акчалата бүләкләү (алга таба – акчалата бүләкләү) билгеләү һәм түләү турында Комитет боерыгы (әлеге Регламентка 5 нче кушымта);

- акчалата бүләкләүне түләүдән баш тарту турында Комитет боерыгы (әлеге Регламентка 6 нчы кушымта).

2.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап Комитетка мөрәҗәгать итүнең үзе сайлаган ысулы нигезендә бирелә (җибәрелә):

язма рәвештә гариза бирүчегә шәхсән яисә тапшыру турында хәбәр белән почта аша юллама белән;

Комитетның вәкаләтле вазыйфаи затының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә имзаланган электрон документ рәвешендә электрон почта адресына яисә Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatarstan.ru), Бердәм порталда гариза бирүченең шәхси кабинетына (алга таба – Республика порталы);

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге (алга таба – КФҮ) аша.

2.3.3. Реестр язмасы дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булмый.

Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе Татарстан Республикасының нинди дә булса дәүләт мәгълүмат системасында теркәлми.

2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты

Сорату (алга таба – гариза) һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар шәхсән яисә почта аша тапшырылган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтүнең максималь срогы гариза һәм документлар Комитетта теркәлгән көннән алып өч ай эчендә бирелә.

Гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар Бердәм

порталда, Республика порталында шәхси кабинет аша бирелгән очракта, Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең максималь срогы – эшләр номенклатурасы һәм Республика порталында, Бердәм порталда шәхси кабинетта чагылдырыла торган «Документларны тикшерү» статусы нигезендә гаризага номер бирелгән көннән алып өч ай.

Гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар КФҮгә бирелгән очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтүнең максималь вакыты – документлар Комитетка тапшырылган көннән алып өч ай.

Гариза бирүче КФҮгә мөрәҗәгать иткәндә, Комитет һәм КФҮ арасында үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле хәбәрнамәне һәм теркәлә торган документларны Комитетка тапшыру тәэмин ителә. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакытына хәбәрнамәнең КФҮдә булу вакыты һәм дәүләт хезмәте нәтиҗәсен Дәүләт комитетыннан КФҮгә тапшыру вакыты кертелми.

Гариза бирүчегә акчалата бүләк түләү тиешле рөхсәтсез саклана торган яки Татарстан Республикасы территориясендә табылган коралны, хәрби кирәк-яракларны, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне үз ихтыяры белән тапшырган гражданнарга акчалата бүләкләү түләүләрне оештыру комиссиясе (алга таба – Комиссия) карар кабул иткән көннән алып 30 эш көне эчендә башкарыла.

Акчалата бүләкләү билгеләү һәм түләү (түләүдән баш тарту) турында карар кабул ителгән көннән алып 10 эш көне эчендә җибәрелә.

Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе гамәлдә булу срогы дәвамында электрон документ рәвешендә акчалата бүләкләүне билгеләү һәм түләү (түләүдән баш тарту турында) турында карар алырга хокуклы.

2.5. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә, гариза бирүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары

Дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен түләү алу Россия Федерациясе законнарында каралмаган.

2.6. Гариза бирүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны биргәндә һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты

Гариза бирүчене кабул итүне (хезмәт күрсәтүне) көтү һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алуның максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

Гариза бирүчеләрнең аерым категорияләре өчен дәүләт хезмәте күрсәтүгә чират билгеләнмәгән.

2.7. Гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризасын теркәү вакыты

Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны теркәү гариза һәм документлар Комитетка кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Республика порталы, Бердәм портал аша электрон рәвештә кергән гариза, Республика порталында, Бердәм порталда гаризаларны автомат рәвештә теркәү булмаган очракта, кергән көнне Комитет тарафыннан билгеләнгән тәртиптә теркәлә.

МФЦ аша гариза кергәндә, гаризаны теркәү гариза һәм документлар кергән көнне башкарыла.

Электрон рәвештә ял (бәйрәм) көнендә кергән гариза ял (бәйрәм) көненнән соң килә торган эш көнендә теркәлә.

2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр.

Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр Комитетның рәсми сайтында, Бердәм порталда һәм Республика порталында урнаштырылган

2.9. Дәүләт хезмәтенең үтемлелеге һәм сыйфаты күрсәткечләре.

Дәүләт хезмәтеннән һәркем файдаланырлык булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре Комитетның рәсми сайтында, Бердәм порталда һәм Республика порталында урнаштырылган.

2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән:

- КФҮдә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү үзенчәлекләрен һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган;

- Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында белешмәләр бирү хакында.

2.10.1 КФҮ аша дәүләт хезмәте күрсәткәндә, консультация бирүне, документлар кабул итү һәм бирүне КФҮ белгече башкара.

Гариза бирүче КФҮ аша мөрәҗәгать иткәндә, гариза һәм документларны Комитетка тапшыру гаризаны теркәгән көнне тәэмин ителә.

Дәүләт хезмәте күрсәткәндә, Комитет белән КФҮнең үзара хезмәттәшлеге тәртибе Комитет белән КФҮ арасында төзелә торган килешү белән, ә КФҮнең гариза бирүчеләр белән хезмәттәшлек тәртибе – КФҮнең эш регламенты белән җайга салына.

КФҮ гариза бирүчеләрдән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар кабул итә, гариза бирүчеләргә дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе, дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы соратуларны үтәү барышы турында, шулай ук дәүләт хезмәтен күрсәтүгә бәйле башка мәсьәләләр буенча хәбәр итә.

КФҮ түбәндәге очракларда дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гаризаны, документларны һәм (яисә) белешмәләрне кабул итүдән баш тартырга хокуклы:

- чистартулар, өстәмәләр белән документлар тапшыру;

- әгәр гариза гариза бирүченең мәнфәгатьләрен яклау вәкаләте булмаган зат тарафыннан бирелгән булса.

КФҮдә гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе бирелә, шул исәптән Комитет тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча Күпфункцияле үзәккә җибәрелгән электрон документларның эчтәлеген раслый торган кәгазь документлар, шулай ук документлар, шул исәптән Комитетның мәгълүмат системаларыннан кәгазьдә төзелгән һәм таныкланган өземтәләр бирелә.

КФҮдә дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе гариза бирүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтүгә гариза Күпфункцияле үзәк аша бирелгән очракта гына бирелергә мөмкин.

Гаризаны һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны гариза бирүченең яшәү урынына яисә булу урынына бәйсез рәвештә кабул итәргә мөмкин.

2.10.2 Гариза бирүче гаризаны электрон документ формасында җибәрә ала, аны рәсмиләштерү тәртибе «Дәүләт һәм (яки) муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәк булган гаризаларны һәм башка документларны электрон документлар рәвешендә рәсмиләштерү һәм тапшыру тәртибе турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 7 июлендәге 553 номерлы карары белән билгеләнгән һәм ул төгәл бер мәгънәле һәм яшерен мәгълүмат, шулай ук электрон рәвештә арадаш хәбәрләр һәм җавап мәгълүматлары җибәрү һәм алу мөмкинлеген тәэмин итә торганРеспублика порталы һәм Бердәм портал аша (техник мөмкинлекләр булганда), шул исәптән 63-ФЗ номерлы Федераль законда каралган тәртиптә гади электрон имза кулланып тапшырыла.

Комитетка Республика порталыннан, Бердәм порталдан файдаланып, электрон документ рәвешендә кергән гаризаны теркәү, гариза бирүчегә аның гаризасын алу турында мәгълүматны үз эченә алган, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны Комитетка тапшыру датасын күрсәтеп, электрон рәвештә хәбәрнамә формалаштыру һәм җибәрү Комитетка гариза кергән көнне автомат рәвештә гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәтен электрон рәвештә күрсәткәндә, гариза бирүче түбәндәгеләргә хокуклы:

1) Бердәм порталда һәм Республика порталында урнаштырылган дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат алырга;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) 16 статьясындагы 1 өлешенең $7^2$ пункты нигезендә электрон образлары элек таныкланган документларны һәм мәгълүматны Бердәм порталдан, Республика порталыннан файдаланып тапшырырга;

3) дәүләт хезмәтен күрсәтү турында электрон рәвештә бирелгән гаризаларны карау барышы турында белешмәләр алырга;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатын бәяләүне гамәлгә ашырырга;

5) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;

6) Комитетның, шулай ук аның вазыйфаи затларының карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) карата Бердәм портал, Республика порталы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелгәндә кылынган карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы аша, федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы аша шикаять бирергә.

Гаризаны формалаштыру нинди дә булса башка формада өстәмә гариза бирү кирәклегеннән тыш гаризаның электрон формасын Бердәм порталда, Республика порталында тутыру юлы белән башкарыла.

Гариза язганда, түбәндәге мөмкинлекләр бирелә:

1) гаризаны һәм хезмәт күрсәтү өчен кирәкле башка документларны күчереп алу һәм саклап калу мөмкинлеге;

2) электрон гариза формасының күчермәсен кәгазьдә бастыру мөмкинлеге;

3) элек электрон гариза формасына кертелгән кыйммәтләрне кулланучы теләге белән теләсә кайсы вакытта, шул исәптән кертү хаталары килеп чыкканда һәм белдерүнең электрон формасына кыйммәтләрне яңадан кертү өчен кире кайтарганда саклау;

4) гариза бирүче ЕСИАда урнаштырылган мәгълүматны һәм, ЕСИАда булмаган мәгълүматларга кагылышлы өлештә Бердәм порталда, Республика порталында басылган мәгълүматларны кулланып мәгълүматны керткәнче, гаризаның электрон формасы кырын тутыру;

5) элек кертелгән мәгълүматны югалтмыйча, гаризаның электрон формасын тутыруның теләсә кайсы этабына кайту мөмкинлеге;

6) гариза бирүченең үзенең элек биргән гаризаларына кимендә бер эчендә, шулай ук өлешчә формалаштырылган гаризаларга кимендә өч ай эчендә керү мөмкинлеге.

2.10.3 Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.10.4 Дәүләт хезмәте күрсәткәндә «Ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы кулланыла.

2.10.5 Татарстан Республикасы Дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүмат мәгълүмати стендларда һәм Комитетның рәсми сайтында урнаштырыла.

2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге.

2.11.1. Гариза бирүче үзе тапшыра торган документларга һәм мәгълүматка һәм ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшырылырга тиеш булган гариза бирүче үз инициативасы белән тапшырырга хокуклы документларга бүленеп, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен закон һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге, яисә андый документларның булмавын күрсәтү шушы Регламентның 3 нче кушымтасында китерелгән.

2.11.2. Гаризаның һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларның формасы әлеге Регламентның 7 нче кушымтасында китерелгән.

2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы соратуны һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге, һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору өчен яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

2.12.1. Хезмәт күрсәтү турындагы соратуны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр:

- гариза вәкаләтләренә дәүләт хезмәте күрсәтү керми торган дәүләт хакимияте органына тапшырылган;

- тапшырылган документлар дәүләт хезмәте сорап мөрәҗәгать иткән вакытка үз көчләрен югалткан (шәхесне раслый торган документ; Гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ, дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап күрсәтелгән зат мөрәҗәгать иткән очракта);

- кәгазьдә тапшырылган документларда Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән тәртиптә расланмаган текстта бетерү һәм төзәтү бар;

- электрон рәвештә тапшырылган документларда дәүләт хезмәте күрсәтү өчен документларда булган мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмдә кулланырга мөмкинлек бирми торган зыяннар бар һәм (яисә) укылмый

- гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар электрон формада, аларны бирү форматына карата таләпләрне бозып тапшырылган һәм (яки) укылмый

-

63-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясында билгеләнгән көчәйтелгән квалификацияле электрон имзаның чынлыгын тану шартларын үтәмәү ачыкланган.

2.12.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр

Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.

2.12.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр:

- акчалата түләү өчен агымдагы финанс елында бюджет йөкләмәләре лимитларының җитәрлек булмавы.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарткан очракта, Комитет 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы $9^1$ өлеше нигезендә гариза бирүчегә мондый баш тартуның сәбәпләре турында, кире кагуга сәбәп булган документлар һәм мәгълүмат исемлеген күрсәтеп, шулай ук федераль законнарда һәм (яисә) башка норматив хокукый актларда билгеләнгән дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тартуга китергән таләпләр исемлеген күрсәтеп хәбәр итә. (әлеге Регламентка 8 нче кушымта).

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәлү вакытлары

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлгә ашырыла торган административ процедуралар исемлеге:

1) гариза бирүченең профилен билгеләү;

2) соратуны, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны һәм (яисә) мәгълүматны кабул итү;

3) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек;

4)4) гариза бирүче һәм (яисә) гариза бирүченең объектлары һәм (яисә) башка объектлар турында белешмәләрне, шулай ук гариза бирүченең белемнәрен (күнекмәләрен) аларның Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килү-килмәү мәсьәләсенә карата бәяләү (дәүләт хезмәтен күрсәтү (бирүдән баш тарту) турында карар кабул итү процедурасы кысаларында тикшерелә торган таләпләрдән тыш) (алга таба – бәяләү процедурасы);

5) дәүләт хезмәте күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар кабул итү;

6) дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү.

3.2. Гариза бирүченең профилен билгеләү гариза бирүчегә анкета бирү юлы

белән башкарыла, аның барышында гариза бирүченең категорияләре (билгеләре) билгеләнә.

Гариза бирүченең категорияләрен (билгеләрен) билгеләү әлеге Регламентка 2 нче кушымта нигезендә гариза бирүченең категорияләрен барышында гариза бирүченең билгеләре күрсәткечләренең тулы исемлеге билгеләнә, аларның һәркайсы гариза бирүче дәүләт хезмәтен алу өчен тапшырырга тиешле документларның билгеле бер исемлегенә туры килә торган чагыштыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

3.3. Соратуны, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны һәм (яисә) мәгълүматны кабул итү.

3.3.1. Гариза бирүченең категорияләре (билгеләре), шулай ук әлеге документларны тапшыру ысуллары нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлеге әлеге Регламентка 3 нче кушымтада китерелгән.

3.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы соратуны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге әлеге Регламентның 4 нче кушымтасында китерелгән.

3.3.3. Комитет гариза бирүченең яшәү урынына яисә булу урынына бәйсез рәвештә дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы соратуны һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итәргә мөмкин.

3.3.4. Гаризаны һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны теркәү гариза Комитетка яисә КФҮгә кергән көнне гамәлгә ашырыла.

3.4. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек

3.4.1. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле соратып алына торган документлар:

салым органында исәпкә кую турында белешмәләр Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән соратыла.

Процедура гаризаны теркәгәннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Ведомствоара мәгълүмати сорату, гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү максатында, күрсәтелгән органнарга җибәрелә.

Процедураларның нәтиҗәсе: тиешле органнарга җибәрелгән соратулар.

3.4.2. Документлар (аларның күчермәләре яки аларда булган мәгълүматлар) бу документлар электрон формада «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кагыйдәләре, шул исәптән Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең башкарма органнары һәм (яисә) җирле үзидарә органнары арасында ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне оештыруның тәкъдим ителә торган кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 23 июнендәге 963 номерлы карары нигезендә тиешле ведомствоара сорату җибәрелгәннән соң 48 сәгатьтән дә соңга калмыйча бирелә. Ведомствоара соратуга җавап бирү срогы күрсәтелгән органнарга ведомствоара сорату кергән көннән алып 15 эш көненнән артмаска тиеш.

Белешмәләрне куллануның максатлары булып гариза бирүче тарафыннан

тапшырылган документларның дөреслеген билгеләү, шулай законнарны һәм гариза бирүченең хокукларын бозуга юл куймый торган карарлар кабул итү тора.

3.4.3. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кәгазьдә башкарылырга мөмкин:

1) соратыла торган белешмәләр электрон формада булмауга бәйле рәвештә электрон ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне гамәлгә ашыра алмаганда;

2) ведомствоара сорату җибәргәндә, кәгазьдә документларның төп нөсхәсен тапшырырга кирәк булганда.

Әгәр ведомствоара хезмәттәшлек кәгазь чыганакта гамәлгә ашырылса, әлеге Регламентка 3 нче кушымтада каралган документлар (аларның күчермәләре яки аларда булган мәгълүматлар) әлеге документлар алар карамагында булган органнар тарафыннан бирелә.

210-ФЗ номерлы Федераль законның $7^2$ статьясындагы 3 өлеше нигезендә ведомствоара соратуларга җавап әзерләү һәм җибәрү вакыты ведомствоара сорату кергән көннән биш эш көненнән артып китә алмый.

Белешмәләрне куллануның максатлары булып гариза бирүче тарафыннан тапшырылган документларның дөреслеген билгеләү, шулай законнарны һәм гариза бирүченең хокукларын бозуга юл куймый торган карарлар кабул итү тора.

Процедураның нәтиҗәсе: ведомствоара соратулар җибәрү өчен җаваплы вәкаләтле затка җибәрелгән сорала торган документларны (аларның күчермәләрен яки андагы белешмәләрне) яки баш тарту турында хәбәрнамәне алу.

3.5. Гариза бирүче турында Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килү-килмәвен бәяләү процедурасы.

3.5.1. Гариза бирүче турындагы белешмәләрнең Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килү-килмәвен бәяләү 15 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

3.5.2. Бәяләү процедурасын Бүлек хезмәткәре үткәрә.

3.5.3. Гариза бирүче тапшырган белешмәләр һәм аларның билгеләнгән таләпләргә туры килүе бәяләү процедурасының объекты булып тора.

3.5.4. Акчалата бүләкләү түләү (түләүдән баш тарту) турындагы карар гариза бирүче документларны КФҮгә тапшырган көннән алып өч ай эчендә Комитет тарафыннан яисә тиешле максатларда төзелгән махсус Комиссия карары нигезендә башка ысул белән кабул ителә.

Күп функцияле үзәктән документлар алганнан соң яисә бүтән ысул белән Комитет аларны бер эш көне эчендә Комиссиягә тапшыра. Комиссия материалларны карый һәм түләү өчен нигезләрнең булуы йә булмавы турында карар чыгара.

Комиссия утырышлары рәислек итүче карары буенча кирәк булган саен, әмма кварталга кимендә 1 мәртәбә уздырыла; утырыш әгъзаларының кимендә 50 % ы катнашында тулы хокуклы дип санала. Карарлар беркетмә белән рәсмиләштерелә, Комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана һәм, утырыштан соң өч эш көненнән дә соңга калмыйча, рәислек итүче тарафыннан раслана. Документларны карауның бөтен процедурасы алдагы процедура тәмамланганнан соң 46 эш көне дәвамында үткәрелә.

Расланган беркетмә нигезендә түләү (яисә түләүдән баш тарту) турында Комитет боерыгы проекты әзерләнә һәм рәсмиләштерелә һәм акчалата бүләкләүне түләү яисә түләүдән баш тарту турында карар кабул ителгән вакыттан алып биш эш көне эчендә рәискә (яисә вәкаләтле затка) имзага җибәрелә.

Рәис (аның вазыйфаларын башкаручы зат) боерыкны раслауга кергән көннән алып ике эш көне эчендә имзалый.

Баш тарту турында карар Регламентның 4 нче кушымтасында санап үтелгән хәлләр булганда кабул ителә.

Соңгы нәтиҗәсе – акчалата бүләкләүне билгеләү һәм түләү турында (түләүдән баш тарту турында) расланган боерык.

3.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар кабул итү.

3.6.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр әлеге Регламентның 4 нче кушымтасында китерелгән.

3.6.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар кабул итү срогы Комитет тарафыннан карар кабул итү өчен кирәкле барлык белешмәләрне алу датасыннан исәпләнә торган срок өч ай тәшкил итә.

3.7. Дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү.

3.7.1. Комитет, гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен гариза бирүчегә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланганнан соң ун эш көне эчендә башкарыла.

3.7.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен бирү гариза бирүченең яшәү урынына яки булу урынына бәйсез рәвештә сайлавы буенча Комитет тарафыннан гына мөмкин.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен җибәрү.

3.7.3. Акчалата бүләкләү түләү.

Акчалата бүләкне түләү Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган шәхси счетыннан акчаны гариза бирүченең гаризада күрсәтелгән счетына күчерү юлы белән акчалата бүләкне билгеләү һәм түләү турындагы карар нигезендә Комитет тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура, Комиссия тарафыннан акчалата бүләк түләү турында карар кабул ителгәннән соң, 30 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүченең реквизитлары гариза бирүче тарафыннан тапшырылган шәхси счетына акчалата бүләкләү күчерү.

3.8. Дәүләт хезмәте алдан (проактив) режимда күрсәтелми.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы соратуны карау статусын үзгәртү турында гариза бирүчегә хәбәр итү ысуллары

Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы соратуны карау статусын үзгәртү турында гариза бирүчегә хәбәр итү түбәндәге ысуллар белән гамәлгә ашырыла:

4.1. Гариза бирүче Комитетка яисә КФҮгә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә

(Комитет белән КФҮ арасында үзара хезмәттәшлек турында килешү булганда).

4.2. Гариза бирүче гариза бирүченең фамилиясен, исемен, атасының исемен (булган очракта), шулай ук гаризаның теркәү номерын яисә гаризаны идентификацияләү мөмкинлеген бирә торган башка белешмәләрне хәбәр иткәндә, Комитет яисә КФҮ телефоны аша.

4.3. Комитетның электрон почтасы аша (гариза бирүче гаризада электрон почта адресын күрсәткәндә).

4.4. Гариза бирүче гаризада күрсәткән почта адресына почта аша җибәрү юлы белән.

4.5. Бердәм порталда һәм Республика порталында гариза бирүченең шәхси кабинетында автомат режимда.

Гариза бирүче, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза биргәндә, гаризаны карау статусын үзгәртү турында мәгълүмат алуның өстенлекле ысулын күрсәтергә хокуклы.

Тиешле рөхсәтсез саклана торган яки Татарстан Республикасы территориясендә табылган коралны, хәрби кирәк-яракларны, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне үз ихтыяры белән тапшырган гражданнарга акчалата бүләкләү билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта (белешмә)

Шартлы билгеләр һәм кыскартулар исемлеге

1. Регламент – тиешле рөхсәтсез саклана торган яки Татарстан Республикасы территориясендә табылган коралны, хәрби кирәк-яракларны, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне үз ихтыяры белән тапшырган гражданнарга акчалата бүләкләү билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты;
2. Дәүләт хезмәте – тиешле рөхсәтсез саклана торган яки Татарстан Республикасы территориясендә табылган коралны, хәрби кирәк-яракларны, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне үз ихтыяры белән тапшырган гражданнарга акчалата бүләкләү билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү;
3. Гариза бирүче – Рөхсәтсез саклана торган яки Татарстан Республикасы территориясендә табылган коралларны, хәрби кирәк-яракларны, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне ирекле рәвештә тапшырган 18 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк гражданнар;
4. Комитет – Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты;
5. Бүлек – Комитетның административ һәм суд практикасы бүлеге;
6. КФҮ – Дәүләт хезмәте «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» Дәүләт бюджет учреждениесе һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең ерактагы эш урыны.
7. Денежное вознаграждение – тиешле рөхсәтсез саклана торган яки Татарстан Республикасы территориясендә табылган коралны, хәрби кирәк-яракларны, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне үз ихтыяры белән тапшырган гражданнарга акчалата бүләкләү билгеләү һәм түләү турында карар;
8. 63-ФЗ номерлы Федераль закон – «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон;
9. Республика порталы – Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы;
10. Бердәм портал – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) Бердәм порталы;
11. Комиссия – тиешле рөхсәтсез саклана торган яки Татарстан Республикасы территориясендә табылган коралны, хәрби кирәк-яракларны, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне үз ихтыяры белән тапшырган гражданнарга акчалата бүләкләү билгеләү һәм түләүне оештыру Комиссиясе;
12. ЕСИА – «Электрон рәвештә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен файдаланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик үзара хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада идентификацияләүнең һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы;
13. 210-ФЗ номерлы Федераль закон – «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон.

Тиешле рөхсәтсез саклана торган яки Татарстан Республикасы территориясендә табылган коралны, хәрби кирәк-яракларны, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне үз ихтыяры белән тапшырган гражданнарга акчалата бүләкләү билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

Гариза бирүчеләрнең категорияләре (билгеләре) идентификаторлары

| № | Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе | Гариза бирүченең аерым билгесе исеме | Гариза бирүчеләрнең аерым билгесе идентификаторы |
|---|---|---|---|
| 1 | Тиешле рөхсәтсез саклана торган яки Татарстан Республикасы территориясендә табылган коралны, хәрби кирәк-яракларны, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне үз ихтыяры белән тапшырган гражданнарга акчалата бүләкләү билгеләү һәм түләү Комитет боерыгы | 18 яшьтән өлкәнрәк гражданнар | 1А |
| | | Вәкил | 2А |

Тиешле рөхсәтсез саклана торган яки Татарстан Республикасы территориясендә табылган коралны, хәрби кирәк-яракларны, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне үз ихтыяры белән тапшырган гражданнарга акчалата бүләкләү билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен документларның тулы исемлеге

| № | Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен документларның исемлеге | Документлар тапшыруга таләпләр | Гариза бирүченең идентификаторы ... | Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бирү ысулы |
|---|---|---|---|---|
| *Тиешле рөхсәтсез саклanучы яисә Татарстан Республикасы территориясендә табылган коралларны, сугыш кирәк-яракларын, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне үз теләге белән тапшырган гражданнарга акчалата бүләкләү билгеләү һәм түләү буенча карар кабул итү өчен документлар исемлеге* | | | | |
| 1 | Акчалата бүләкләү билгеләү һәм түләү турында гариза<br><br>Электрон формадагы гариза | Регламентка 7 нче кушымта нигезендә<br><br>63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә имзаланган гаризаның электрон формасына тиешле белешмәләр кертү юлы белән pdf, jpg, jpeg, png, tif, doc, docx, rtf, sig форматындагы 50 Мбайттан зур булмаган файллар рәвешендә тутырыла. Тапшырыла торган электрон документларның сыйфаты документ текстын тулысынча укырга һәм документ реквизитларын танырга мөмкинлек бирергә тиеш. | 1А,2А | Шәхсән Комитетка, Россия почтасы аша<br>Бердәм портал, Республика порталы, КФҮ |
| 2 | Шәхесне таныклый торган документ | Россия Федерациясе гражданы паспорты яисә шәхесне таныклый торган башка документ | 1А,2А | КФҮгә яисә турыдан-туры Комитетка мөрәҗәгать иткәндә |
| 3 | Гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ | законнар нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә. | 2А | Почта аша җибәргәндә, КФҮгә яисә турыдан-туры |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | Комитетка мөрәҗәгать иткәндә |
| 4 | (коралның, сугыш кирәк-яракларының, коралга патроннарның, шартлаткыч җайланмалар һәм шартлаткыч матдәләрне кабул итү турында квитанция | Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең территориаль органнарыннан яисә Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгыннан | 1А,2А | Шәхсән Комитетка, Россия почтасы аша Бердәм портал, Республика порталы, КФҮ |
| 5 | Акчалата бүләкләү күчереләчәк счет реквизитлары | Счетны һәм ул ачылган кредит учреждениесен идентификацияли торган банк реквизитлары | 1А,2А | Шәхсән Комитетка, Россия почтасы аша Бердәм портал, Республика порталы, КФҮ |
| *Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында гариза бирүче үз инициативасы белән тапшырырга хокуклы документлар* | | | | |
| 1 | Гариза бирүчене салым органында исәпкә кую турында таныклык күчермәсе | Федераль салым хезмәтеннән | 1А,2А | Шәхсән Комитетта, Россия почтасы аша Бердәм портал, Республика порталы, КФҮ |

Тиешле рөхсәтсез саклана торган яки Татарстан Республикасы территориясендә табылган коралны, хәрби кирәк-яракларны, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне үз ихтыяры белән тапшырган гражданнарга акчалата бүләкләү билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта

Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы соратуны һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен кирәкле нигезләрнең тулы исемлеге, һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору өчен яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

| № | Хезмәт күрсәтү турындагы гаризаны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр исемлеге | Гариза бирүчеләрнең аерым билгесе идентификаторы |
|---|---|---|
| *Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы соратуны һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр исемлеге* | | |
| 1 | гариза вәкаләтләренә дәүләт хезмәте күрсәтү керми торган дәүләт хакимияте органына тапшырылган | 1А,2А |
| 2 | тапшырылган документлар дәүләт хезмәте сорап мөрәҗәгать иткән вакытка үз көчләрен югалткан (шәхесне раслый торган документ; Гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ, дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап күрсәтелгән зат мөрәҗәгать иткән очракта) | 1А,2А |
| 3 | кәгазьдә тапшырылган документларда Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән тәртиптә расланмаган тәртиптә текстта бетерү һәм төзәтү бар | 1А,2А |
| 4 | электрон рәвештә тапшырылган документларда дәүләт хезмәте күрсәтү өчен документларда булган мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмдә кулланырга мөмкинлек бирми торган зыяннар бар һәм (яисә) укылмый | 1А,2А |
| 5 | гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар электрон формада, аларны бирү форматына карата таләпләрне бозып тапшырылган һәм (яки) укылмый | 1А,2А |
| 6 | 63-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясында билгеләнгән көчәйтелгән квалификацияле электрон имзаның чынлыгын тану шартларын үтәмәү ачыкланган; | 1А,2А |
| *Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр исемлеге* | | |
| 1 | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган | 1А,2А |
| *Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр исемлеге* | | |

| | | |
|---|---|---|
| 1 | акчалата түләү өчен агымдагы финанс елында бюджет йөкләмәләре лимитларының җитәрлек булмавы | 1А,2А |

Тиешле рөхсәтсез саклана торган яки Татарстан Республикасы территориясендә табылган коралны, хәрби кирәк-яракларны, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне үз ихтыяры белән тапшырган гражданнарга акчалата бүләкләү билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 5 нче кушымта

Форма

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИОЛОГИК РЕСУРСЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

Приказ Казан шәһәре Боерык

__________ № ___- од

Акчалата бүләкләү билгеләү һәм түләү турында карар

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 1995 елның 05 августындагы 545 номерлы карары белән расланган Тиешле рөхсәтсез саклана торган яки Татарстан Республикасы территориясендә табылган корал, хәрби кирәк-яраклар, корал патроннары, шартлаткыч җайланмалар һәм шартлаткыч матдәләр ирекле рәвештә тапшырган гражданнарга акчалата бүләкләр түләү эшен оештыру турындагы нигезләмәгә ярашлы рәвештә һәм Рөхсәтсез саклана торган яки Татарстан Республикасы территориясендә табылган коралларны, хәрби кирәк-яракларны, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне үз ихтыяры белән тапшырган гражданнарга акчалата бүләкләү түләүне оештыру комиссиясенең _______________________ бәяләмәсе нигезендә боерам:

Рөхсәтсез саклана торган яки Татарстан Республикасы территориясендә табылган коралларны, хәрби кирәк-яракларны, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне үз ихтыяры белән тапшырган гражданга

________________________________________________________________________________

(Ф.И.А. (соңгысы – булганда))

акчалата ________________ сум күләмендә бүләкләү билгеләргә һәм түләргә.

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты Рәисе

__________________________

(Ф.И.А. (соңгысы – булганда))

Тиешле рөхсәтсез саклана торган яки Татарстан Республикасы территориясендә табылган коралны, хәрби кирәк-яракларны, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне үз ихтыяры белән тапшырган гражданнарга акчалата бүләкләү билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 6 нчы кушымта

Форма

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИОЛОГИК РЕСУРСЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

Приказ Казан шәһәре Боерык

__________ № ___- од

Акчалата бүләкләү түләүдән баш тарту турында карар

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 1995 елның 05 августындагы 545 номерлы карары белән расланган Тиешле рөхсәтсез саклана торган яки Татарстан Республикасы территориясендә табылган корал, хәрби кирәк-яраклар, корал патроннары, шартлаткыч җайланмалар һәм шартлаткыч матдәләр ирекле рәвештә тапшырган гражданнарга акчалата бүләкләр түләү эшен оештыру турындагы нигезләмәгә ярашлы рәвештә һәм Рөхсәтсез саклана торган яки Татарстан Республикасы территориясендә табылган коралларны, хәрби кирәк-яракларны, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне үз ихтыяры белән тапшырган гражданнарга акчалата бүләкләү түләүне оештыру комиссиясенең _______________________ бәяләмәсе нигезендә боерам:

Рөхсәтсез саклана торган яки Татарстан Республикасы территориясендә табылган коралларны, хәрби кирәк-яракларны, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне үз ихтыяры белән тапшырган гражданга
______________________________________________________________
(Ф.И.А. (соңгысы – булганда))
акчалата бүләкләү түләүне кире кагарга.

Баш тарту сәбәбе: _______________________________________________________

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты Рәисе _________________________
(Ф.И.А. (соңгысы – булганда))

Тиешле рөхсәтсез саклана торган яки Татарстан Республикасы территориясендә табылган коралны, хәрби кирәк-яракларны, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне үз ихтыяры белән тапшырган гражданнарга акчалата бүләкләү билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 7 нче кушымта

Форма

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетына
кемнән
_________________________________________
_________________________________________,
(Ф.И.А. (соңгысы – булганда))
яшәү (теркәлү) адресы:
_________________________________________
_________________________________________
Чынлыкта яшәү адресы:
_________________________________________
_________________________________________
паспорты: серия _________ номер _____________
бирелгән «__» _____________________________

Акчалата бүләкләү билгеләү һәм түләү турында гариза

Ихтыяри тапшырылган корал өчен миңа акчалата бүләк түләүне билгеләвегезне сорыйм ______________________________________________________________________________

(коралның, сугыш кирәк-яракларының, коралга патроннарның, шартлаткыч ______________________________________________________________________________ җайланмалар һәм шартлаткыч матдәләрнең атамасы)
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
(корал, сугыш кирәк-яраклары, коралга патроннар, шартлаткыч җайланмалар һәм шартлаткыч матдәләр кабул итү квитанциясенең номеры һәм дата)

Гаризага түбәндәге документлар беркетелә:
1) ______________________________________________________________________
2) ______________________________________________________________________
3) ______________________________________________________________________
4) ______________________________________________________________________
5) ______________________________________________________________________.

Акчалата бүләкне билгеләү һәм түләү турында карарны түбәндәгечә алырга риза:
электрон документны E-mail адресына ______________________________________________;
расланган күчермә рәвешендә кәгазьдә почта аша _________________________ _______________________________ адресына; башка юл белән ________________________________________________________ .

Моның белән раслыйм: гаризага кертелгән минем шәхесемә һәм мин тәкъдим иткән затка кагылышлы мәгълүматлар, шулай ук түбәндә мин керткән мәгълүматлар дөрес. Гаризага

беркетелгән документлар (документлар күчермәләре) гариза биргән вакытта Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләргә туры килә, гариза тапшырылган вакытта бу документлар гамәлдә һәм алардагы мәгълүматлар ышанычлы.

Миңа күрсәтелгән дәүләт хезмәтенең сыйфатын бәяләү буенча __________ телефоны аша сораштыруда катнашырга ризалыгымны бирәм.

_____________ _________________________ _________________________________
(дата) (гариза бирүченең (вәкаләтле вәкилнең) имзасы) (Ф.И.А. (соңгысы – булганда))

Тиешле рөхсәтсез саклана торган яки Татарстан Республикасы территориясендә табылган коралны, хәрби кирәк-яракларны, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне үз ихтыяры белән тапшырган гражданнарга акчалата бүләкләү билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 8 нче кушымта

Форма

Документларны кабул итүдән баш тарту турында хәбәрнамә

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты хәбәр итә...
_________________________________________________________________
(физик затның Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта)),
_________________________________________________________________
паспорт мәгълүматлары, теркәлү адресы)
_________________________________________________________________

_________________________________________________________________
(дәүләт хезмәте атамасы)

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен документлар кабул итүдән баш тарту турында хәбәр итә.

Баш тарту сәбәбе: ___________________________________________________

_________________ _______________ _______________________________
(вазыйфасы) (имза) (Ф.И.А. (соңгысы – булганда))